**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.08.2016 Балык Бистәсе штп. № 133пи

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2014 елның 9 сентябрендәге 161п номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә карар бирәм:

1.Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2014 елның 9 сентябрендәге 161п номерлы карарына (Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 15 июлендәге 195пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарга кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Җитәкче Р.Х.Хабибуллин

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 9 сентябрендәге 161п номерлы карарына (Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 17 августындагы № 133 пи карары редакциясендә) кушымта

**Татарстан Республикасы административ хокук бозулар кодексының 2.6, 2.8, 2.14, 3.2 - 3.8, 3.10, 3.11, 3.14 - 3.16, 5.1, 5.2, 5.6 матддәләрендә каралган административ хокук бозулар турында үз компетенцияләре чикләрендә беркетмәләр төзергә вәкаләтле затлар исемлеге**

I. Татарстан Республикасы административ хокук бозулар кодексының 2.6, 2.8, 2.14, 3.2, 3.16, 5.1, 5.2, 5.6 маддәләрендә каралган административ хокук бозулар турында үз компетенцияләре чикләрендә беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар

- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы;
-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы урынбасары.

II. Татарстан Республикасы административ хокук бозулар кодексының 2.6,3.3-3.7, 3.10, 3.16 маддәләрендә каралган административ хокук бозулар турында үз компетенцияләре чикләрендә беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар

- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак–коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы;
- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары.

III. Татарстан Республикасы административ хокук бозулар кодексының 3.8, 3.11, 3.14, 3.15 маддәләрендә каралган административ хокук бозулар турында үз компетенцияләре чикләрендә беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау пунктлары эшчәнлеген тәэмин итү секторының әйдәп баручы белгече (балигъ булмаганнар арасында гаилә иминлеген һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча инспектор)